ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.11.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3116**

2026 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарны раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Федераль законның 99 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуга кушымтада бирелгән норматив чыгымнарны расларга.
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә әлеге карарның 1 пункты белән расланган гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru ) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасары -Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 13 ноябрендәге
3116 номерлы карары белән
расланган

**2026 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

<table>
<tr><th>Гомуми белем бирү оешмасы тибы һәм төре</th><th>Территориаль урнашуы</th><th>Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, бер елга сумнарда</th></tr>
<tr><td rowspan="2">Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат</td><td>шәһәр җирлеге</td><td>135849</td></tr>
<tr><td>авыл җирлеге</td><td>137122</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Гомуми белем бирү мәктәп-интернат</td><td>шәһәр җирлеге</td><td>205458</td></tr>
<tr><td>авыл җирлеге</td><td>209941</td></tr>
</table>